**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 25 16 февраль 2016 ел.

Мәлбагыш авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мәлбагыш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Мәлбагыш авылы башкарма комитетының 2016 елның 29 январендә чыккан 2 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 29 январь 2016 елда чыккан 24 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте :

1. Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 17 апрель 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - авыл җирлеге биләмәсен төзекләндерү өчен ( урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнарга һәм йортларга урам исемнәре, йорт номерлары урнаштыру, кечкенә архитектура формалары кую һәм төзекләндерү) - кышын авылдагы юлларны кардан чистарту өчен, үзарасалым акчасының 8 мең сум күләмендәгесе Мәлбагыш авылы өчен, 5 мең сум күләмендәгесе Түбән Якый авылы өчен, 2 мең сум күләмендәгесе Каменка авылы өчен;

- авыл җирлеге биләмәсендә халыкны су белән тәэмин итү – Түбән Якый авылына су кертү буенча проект документаөиясе ясату өчен, узарасалым күләменең 80 мең сумы;
- соңгы юлга озатуны оештыру һәм зиаратларның тотымы – Түбән Якый авылы зиараты ихатасын әйләндереп алу өчен узарасалым күләменең 48 мең 750 сумы

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис И.А.Ахтямова